## Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында гражданнар җыены карары

2024 елның 22 ноябре

№ 3

### Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2024 елның 22 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәү урыны Иске Куак авыл җирлеге чикләрендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән, бала чактан инвалидлар, I, II төркем инвалидлар, көндезге бүлектә укучы студентлар, сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, мобилизацияләнгән гражданнар, контракт буенча хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) Ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Иске Куак авылындагы яңа зиратта киртәләр кору).
2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Куак авылында, Совет урамы буенча юлдагы чокырларны вак таш җәеп ремонтлау).
3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Кувак авыл җирлеге территориясендә үлән чабу) соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 564 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 338 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 338 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәү урыны Иске Куак авыл җирлеге чикләрендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән, бала чактан инвалидлар, I, II төркем инвалидлар, көндезге бүлектә укучы студентлар, сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, мобилизацияләнгән гражданнар, контракт буенча хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) Ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Иске Куак авылындагы яңа зиратта киртәләр кору).
2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Куак авылында, Совет урамы буенча юлдагы чокырларны вак таш җәеп ремонтлау) .
3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Кувак авыл җирлеге территориясендә үлән чабу) соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин ур., 36 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Иске Куак авыл җирлеге башлыгы

И.Н.Сушкова